Мин урманда йөрергә яратам. Аның гүзәл чагы ноябрь беткәндә, декабрь башланганда була. Анда зифа наратлар, нәфис каеннар үсә. Алар сихри табигатьнең матурлыгын мактап тибрәләләр. Ә миләштән дә күркәмрәк агач юктыр урманда.



# Асыл сыйфатның дәрәҗәләре

| № | Дәрәҗә | Дәрәҗә күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | гади(төп) | ______ |
| 2 | чагыштыру | -рак/рәк кушымчасы |
| 3 | артыклык | а) иң, тома, шыгрым, шыр, чалт, үтә, дөм кисәкчәләре<br>ә) беренче иҗекнең –п, -м, -мь хәрефләрен өстәү юлы белән кабатлануы<br>б) бер үк сыйфатның кабатлануы |
| 4 | кимлек | -гылт/гелт, -кылт/келт, -сыл/сел,<br>-су, -ылҗым/елҗем, -кылтым/келтем, -мса/мсә кушымчалары |

# Кыш

Менә ... кыш та килеп җитте. Бөтен җирне ... кар каплады. Кешеләр ... киемнәрен киделәр.

... урман да бик матур. ... агачның ... ботакларына мамыктай йомшак бәс кунды.

Г.Бакир

бәс- иней

*Файдалану өчен сүзләр*: кышкы, җылырак, соргылт, нәфис, ап-ак, салкын.

Менә җылы җәй дә килеп җитте. Бөтен җирне яшел үлән каплады. Кешеләр җиңел киемнәрен киделәр.


Җәйге урман да бик матур. Соргылт агачның нәфис ботаклары яшел яфракка төренде.



Тест



Яңа төшенчәләр һәм күнекмәләр формалаштыру



Грамматик категорияләре иң аз булган сүз төркеме?

а) исем

ә) фигыль

б) сыйфат



Сораулар

Иҗади эшләр





Йомгаклау



Гомумиләштер еп, нәтиҗә ясау



# Тест




1. Грамматик категорияләре иң аз булган сүз төркеме?
   а) исем
   ә) фигыль
   б) сыйфат
2. Кайсы төркемдә нисби һәм асыл сыйфатлар бар?
   а) тигез, җылы, юаш
   ә) гүзәл, кичке, усал
   б) төче, яссы, кыска
3. Кайсы сыйфатта артыклык дәрәҗәсе кисәкчә ярдәмендә ясалган?
   а) иң яхшы
   ә) җете кызыл
   б) алдагы ике вариантта да
4. Сыйфат җөмләдә күбесенчә нинди җөмлә кисәге була?
   а) аергыч
   ә) хәбәр
   б) ия
5. Асыл сыйфатның ничә дәрәҗәсе бар?
   а) 3
   ә) 5
   б) 4
6. **Үзенә бертөрле кызыклы, катлаулы тормыш кайный иде бу кырмыска оясында** җөмләсендә **катлаулы** сыйфатының сыйфатланмышы
   а) оясында
   ә) кырмыска
   б) тормыш
7. Ялгыш фикерне тап.
   а) тамыр сыйфатлар: тозлы, әче, йонлач
   ә) ясалма сыйфатлар: кышкы, көзге, җәйге
   б) парлы сыйфатлар: зур-зур, иске-москы, язгы-көзге
8. **Идел Агыйделдән озынрак** җөмләсендә **озынрак** сыйфаты
   а) гади дәрәҗәдә
   ә) кимлек дәрәҗәсендә
   б) чагыштыру дәрәҗәсендә

# Жаваплар



1. б
2. ә
3. б
4. а
5. б
6. б
7. а
8. б



Эшләрне бәяләү

**“5” - хатасыз**

**“4” - 1- 3 хата**

**“3” - 4 - 5 хата**

Молодцы!

Булдырдыгыз!

